СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**Кәче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“26” гыйнвар 2016 ел** **№ 12**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Кәче авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Кәче авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Кәче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) һәм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Кәче авылындагы Сәйдәш, Тынычлык, Тау асты урамы юлларна вак таш җәю; | 41600 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Күмү урыннарын карап тору | - зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту;<br>Кәче авылы<br>Чулпан авылы | <br><br>64000<br>20000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | Кәче авылында яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру | 14000 |
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Якты-Көн авылында коены төзекләндерү | 8000 |
| | | Барлыгы: | 152100 |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк ур., 200 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин ур., 22а йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Якты-Көн авылы,

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Т.Д.Закиров

СОВЕТ КАЗЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ